## Сүзлекнең төзелеше

1. Сүзлектә төрек телендә төрле тармакларда киң кулланылган сүзләр, атамалар һәм тотрыклы сүзтезмәләр китерелде.
2. Сүзлек мәкаләсе түбәндәге өлешләрдән гыйбарәт:

а) тәрҗемә ителә торган баш сүздән, ул үзенең башлангыч формасында бирелде:
**arda** *и.* маяк...

б) сүзнең грамматик тасвирламасыннан, аның кайсы сүз төркеменә каравы күрсәтелде:
**dolay** *и.* әйләнә-тирә, тирә-юнь, мохит;
**düzensiz** *с.* 1) тәртипсез, җыйнаксыз; 2) аһәңсез; кәйсез (*музыка*);
**değiştirmek** *ф.* 1) үзгәртү; 2) алмаштыру, алыштыру

в) баш сүзнең төп мәгънәләренең тәрҗемәсеннән: **kabaklık** *и.* 1) өлгермәгәнлек; пешмәгәнлек (*кавын, карбыз тур.*); 2) пеләшлек; 3) *күч.* билгесезлек
**kahretmek** *ф.* 1) җимерү, туздыру; 2) җәзалау, интектерү; 3) каргау; рәнҗү

г) кайбер ике төрле аңлашыла торган тәрҗемәләрдән соң җәя эчендә кыскача бирелгән аңлатмадан:
**mala** *и.* көрәкчек, кельма (*ташчы коралы*)
**Nişanci** *и. астр.* Укчы (*зодиак'тагы йолдызлык исеме*)

д) турыпочмак (□) билгесеннән соң китерелгән, компонентлары аерым язылган кушма сүзләрдән, атамалардан һәм аларның тәрҗемәсеннән:
**ordu** *и.* 1) армия, гаскәр; *ordu merkezi* армия штабы; *sömürge ordusı* колониаль гаскәрләр; 2) *күч.* кешеләр тупламы; чиру □ ordu evi офицерлар йорты

е) ромб (◊) билгесеннән соң бирелгән аерым фразеологик берәмлекләрдән һәм мәкальләрдән:
**ray** *и.* рельс; *ray başlığı* тупик ◊ rayına girmek эзенә төшү, җайлану

3. Баш сүзләр һәм мәкалә эчендәге кушма сүзләр, атамалар, фразеологик берәмлекләр, шулай ук җәясез гарәп саннары ярым калын хәрефләр белән китерелде:

**sabretmek** *ф.* сабыр итү, түзү ◊ sabreden derviş muradına ermiş сабыр иткән морадына җиткән
**safra** I *и.* 1) үт; 2) үт куыгы □ safra kesesi үт куыгы ◊ safra bulanmak (kabarmak) күңел болгану

4. Мәкаләдәге барлык шартлы билгеләр (тамгалар), мисаллар һәм җәя эчендәге аңлатмалар курсив белән бирелде:

**un** *и.* он; *buğday unu* бодай оны; *patates unu* крахмал, бәрәңге оны
**uzaklaştırmak** *ф.* 1) ераклаштыру; ерагайту; 2) алу, чыгару (*эшеннән*)

5. Тәрҗемәләр гадәти (якты) туры хәрефләр белән бирелде:

**üç** *сан.* 1) өч; *üç saat* өч сәгать; *saat üç* сәгать өч (вакыт); 2) өч, өчле (*билге*) □ üç dilli өч телле; üç köşeli өч почмаклы ◊ üç buçuk аннан-моннан, ярым-йорты

6. Сүзләрнең, шул исәптән кушма сүзләрнең, фразеологик берәмлекләрнең аерым мәгънәләренең тәрҗемәсе җәяле гарәп саннары белән аерылды:

**ezilmek** *ф.* 1) изелү, онталу, ваклану; 2) сытылу; 3) *күч.* изелү, изүгә дучар

булу

**alevlenmek** *ф.* 1) ялкынлану; 2) *куч.* кискенләшү

7. Төрек телендәге бер сүз татар телендә ике сүз төркеме мәгънәсенә туры килгәндә, андый сүз ике сүз төркеме сүзләре белән тәрҗемә ителде:

**acı** 1. *с.* ачы; *acı biber* ачы борыч; 2. *и. куч.* кайгы, хәсрәт... minicik 1. *с.* нәни, кечкенә. 2. *и.* сабый, нәни бала

8. Язылышы яки яңгырашы ягыннан бердәй, әмма мәгънәләре белән төрле булган сүзләр (омонимнар), нечкә рим саннары белән билгеләнеп, аерым-аерым бирелделәр:

**nefis** I *и.* нәфес ◊ nefsine düşkün үз нәфесен кайгыртучы, эгоист

**nefis** II *с.* гүзәл, матур, нәфис

9. Исемнәр баш килеш формасында *и.* тамгасы белән бирелделәр, һәм шул ук формада тәрҗемә ителделәр:

**kapan** *и.* капкын, ау, тозак kedi *и.* песи, мәче

10. Сүзлектә төрек теленең фигыльләре нигез формасында китерелеп, аңардан соң сызыкча куелды һәм *ф.* тамгасы белән аның фигыль икәне күрсәтелде:

**kenetlemek** *ф.* ныгыту, беркетү; тоташтыру

11. Төрек фигыльләре татар теленә исем фигыль формасы белән тәрҗемә ителделәр:

**ilgilenmek** *ф.* кызыксыну

**iliklemek** *ф.* эләктерү

12. Башка сүз төркемнәренә кергән сүзләр дә сүзлектә тиешле тамгалар белән үз урыннарын алдылар. Сүз төркемнәрен күрсәткән тамгаларның аңлатмасы кыскартылмалар исемлегендә бирелде.

13. Төрек телендә еш кулланылган атамалар шулай ук сүзлектә бирелделәр. Аларның кайсы өлкәгә каравы тиешле билгеләр белән күрсәтелде:

**acıçiğdem** *и. бот.* эт үләне

**ankebut** *и. зоол.* үрмәкүч

**özdek** *и.* 1) *фәлс.* материя; матдә; 2) агач кәүсәсе; үсемлек сабагы

**paralel** *и.* 1) *геогр.* параллель; 2) параллель сызык; 3) *мат.* параллель

**alarga** *ы. диңг* (*сигнал сүзе*) әйләнеп үт! якынлашма!

**dragon** I *тар.* драгун (*атлы гаскәр*)

14. Стилистик төсмерләре булган сүзләрнең аерым тамгалар белән стилистик үзенчәлекләре күрсәтелде:

**garip** *с.* 1) читтә йөрүче; зимагур; 2) *сөйл.* серле, аңлашылмас

**geçmek** *ф.* 1) *төрле мәгъ.* кичү; 2) күчү, күченү; ... 10) *кит.* теркәлү; ... 14) *эвф.* үлү, кичү *кит.*

**götürüm** *и. сөйл.* сабырлык

15. Сүзләрнең күчмә мәгънәсе *куч.* тамгасы белән тәрҗемә ителде:

**dümen** *и.* 1) (*су һәм һава транспортларында*) руль; 2) *куч.* хәйлә, астан идарә итү

16. Кайбер төрек сүзләрен тәрҗемә иткәндә, татар теленең диалекталь сүзләре дә файдаланылды, андый сүз *диал.* тамгасы белән күрсәтелде:

**anneanne** *и.* дәү әни, нәнәй *диал.*

**evirmek** *ф.* 1) әверү, әверелдерү; 2) әйләндерү □ evirmek çevirmek бер урыннан икенче урынга күчерү; әверү-чәверү *диал.*

17. Төрек телендәге күпмәгънәле баш сүзгә татар телендә дә бер генә сүз туры килгәндә, барлык мәгънәләргә шул бер сүз генә эквивалент итеп бирелде:

**yağ** *и.* май...

18. Теге яки бу мәгънәгә аерым очракларда тәрҗемә җиңел аңлашылсын өчен мисал да китерелде:

**varmak** *ф.* 1) килү, килеп җитү, барып җитү; *tren Ankara'ya yedide varır*

Анкарага поезд җидедә килә; 2) җитү; *yaşı elliye vardı* яше иллегә җитте

19. Этнографиягә караган сүзләргә, экзотик атамаларга тасвирый аңлатмалар китерелде:

**pabuç** *и.* 1) аяк киеме; 2) урындык (өстәл) аякларына кидерелгән металл яки пластик аслык ◊ pabuç eskitmek (*бер эш артыннан*) чабата туздырып йөрү

**kaçamak** *и.* кукуруз оныннан пешерелгән майлы ашамлык

20. Бер мәгънә эчендә тәрҗемәдә китерелгән синонимнар өтер аша бирелделәр. Мәгънәләре белән ераграк яки ерак булган тәрҗемәләр нокталы өтер аша аерылдылар.